**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«17» август 2018 ел Яр Чаллы № 3853

Район башкарма комитеты икътисад бүлегенең муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карар, Башкарма комитет җитәкчесенең 2018 елның 6 августындагы № 3794 «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында», карарына таянып

**Карар бирәм:**

1. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2 .Башкарма комитет җитәкчесенең "Район Башкарма комитетының икътисад бүлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 ел, 21 апрель, 1577 нче карары үз көчен югалткан дип санарга
3.Карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Л. Г. Авзалов